Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Урта Кумор авыл җирлеге Советы

КАРАР

30.09.2021 ел №24

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Урта Кумор авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел утыртмаларны кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы прокуратурасының 2021 елның 30 июнендәге таләбе нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Урта Кумор авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел утыртмаларны кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлеге Советының 2021 елның 15 февралендәге 4 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Урта Кумор авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә керми торган яшел утыртмаларны кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.11 пунктында «рөхсәт ителергә мөмкин» сүзләрен «рөхсәт ителә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Башкарма комитет гариза бирүченең хат-гаризасы, яшел утыртмаларны табигый (натурный) техник тикшерү акты, киселгән агач өчен бәяне (түләү) исәпләү нигезендә, Урта Кумор авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 23 сентябрендәге 13 номерлы карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентында билгеләнгән срокта, авыл җирлеге территориясендә яшел утыртмаларны кисүгә рөхсәт проектын әзерли»;

1.3. Нигезләмәнең 3.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле икенче җөмләне өстәргә: «Киселгән агач өчен бәяне (түләүне) исәпләү «Урман ресурслары күләме бирәмлеге өчен һәм федераль милектәге урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 22 маендагы 310 номерлы карары белән расланган ставкалар нигезендә исәпләнә».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы

буенча, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Урта Кумор авыл җирлегенең рәсми сайтында http://kukmor.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җирлек башлыгы Ю.И.Исынбаев